ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 392-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Л.Р. Кадермәтова, А.И. Җиһаншин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 392-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1852-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
А.К. Хамаев,
Л.Р. Кадермәтова,
А.И. Җиһаншин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:
а) 1 өлешнең өченче абзацында «терлекчелек продуктларының» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;
б) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяның 7 пунктында «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

4) 3 бүлек исемендә «терлекчелек продукциясенең» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;

5) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«14 статья. **Хайваннарны үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлау, төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау, капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызу**

1. Хайваннарны үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыгын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару өчен файдаланыла торган капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлаганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм капиталь ремонтлаганда, капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызганда хайваннарны асрау һәм терлек продукциясен җитештерү өчен үтәлеше мәҗбүри федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) предметына керә торган тиешле таләпләргә туры килерлек шартлар тудыру, шул исәптән хайваннарның йогышлы авырулары килеп чыгуны һәм таралуны кисәтү, хайван асраганда һәм терлек продукциясен җитештергәндә барлыкка килә торган калдыклар белән әйләнә-тирә мохитнең пычрануын кисәтү максатларында, каралырга тиеш.

2. Хайваннарны үстерүгә һәм асрауга (хайваннарны эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган шәхси куллану өчен үстерүдән һәм асраудан тыш), терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле капиталь төзелеш объектын төзү һәм (яисә) капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызу планлаштырыла торган мондый капиталь төзелеш объектын, капиталь булмаган төзелмә, корылма урнаштыруның федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеген) предметына керә торган мәҗбүри таләпләргә туры килүе турында федераль дәүләт ветеринария контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органның бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә.»;

6) 16 статьяда:

а) исемдә «терлекчелек продукциясен» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә «терлекчелек продукциясен» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

7) 17 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

8) 18 статьяда:

а) татарча текстта 18 статья исеме үзгәрешсез кала;

б) 1 өлештә:

татарча текстта беренче абзац үзгәрешсез кала;

икенче абзацта «терлекләрне асрауга, терлекчелек продуктларын җитештерүгә, эшкәртүгә, саклауга һәм сатуга бәйле объектларны» сүзләрен «терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга бәйле объектларны» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «терлекчелек продуктларының» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга, «шушы продуктларны» сүзләрен «шушы продукцияне» сүзләренә алмаштырырга;

9) 19статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә хайваннарны һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу**

1. Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә ветеринария өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясында күрсәтелгән затлар күрсәтмәләре буенча кабул ителә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе, юкка чыгару максатларында, милекчегә шушы тартып алу турында тиешле документ биреп, тартып алынырга мөмкин.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән очракларда хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе милекчесе юкка чыгару максатларында хайваннарны һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу нәтиҗәсендә күргән зыянны тартып алынган һәм юк ителгән хайваннарның һәм (яисә) терлек продукциясенең «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясы нигезендә чикләү чаралары (карантин) билгеләү турында карар кабул ителгән көнгә кадәрге көнгә билгеләнгән бәясенә тигез күләмдә түләттерү хокукына ия.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе бәясе Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түләнә.

4. Хайваннарның һәм (яисә) терлек продукциясенең милекчесе һәм (яисә) хуҗасы тарафыннан хайваннарны үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга бәйле объектларда ветеринария өлкәсендәге законнарны бозулар һәм федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) кысаларында билгеләнгән хокук бозулар ачыкланган очракта, бу объектларда хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килгәндә һәм таралганда, милекчегә хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан киметелергә яисә хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү кире кагылырга мөмкин.

5. Зыянны түләү күләме киметелергә мөмкин булган очракларның исемлеге, мондый күләмне киметү тәртибе һәм зыянны түләү кире кагылырга мөмкин булган очраклар исемлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

6. Тартып алына торган хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен билгеләүгә, хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү күләмен киметү

турындагы карарга яисә хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләүне кире кагу турындагы карарга хайваннар һәм (яисә) терлек продукциясе милекчесе тарафыннан судта шикаять белдерелергә мөмкин.

7. Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары исемлеге һәм хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юкка чыгарганда хайваннарны һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу тәртибе Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.»;

10) 21 статьяның 3 өлешендә «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерү максатыннан эшләнде. Бу зарурлык «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 19 статьясына һәм «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 июнендәге 222-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә барлыкка килде.

Әлеге Федераль законнар белән «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертелде. Алар терлекчелек продуктларын җитештерү һәм саклау өчен каралган биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) планлаштыру һәм төзү мәсьәләләре, шулай ук аеручa куркыныч булган хайван авырулары чыганакларын юк иткәндә хайваннарны һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу мәсьәләләренә кагыла.

Шулай ук федераль законнарда кулланыла торган терминологиягә төзәтмәләр кертелде.

Закон проектында федераль законнардагы әлеге үзгәрешләрне «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законында чагылдыру тәкъдим ителә.

Моннан тыш, закон проектында әлеге Татарстан Республикасы Законын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерүгә юнәлдерелгән нигезләмәләр дә бар. Алар Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының исеменә кагыла.

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертүне таләп итә:

1) «Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына;

2) «Хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продуктларын тартып алуга бәйле рәвештә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 018 елның 14 февралендәге 84 номерлы карарына;

3) «Эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар ясау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар күләмен исәпләү методикасын раслау турында» 2022 елның 3 маендагы 411 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына;

4) «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.